БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«27» 03 2025 ел

**КАРАР**
№ 122

Балтач муниципаль районы һәм аның составына кергән авыл җирлекләре территориясендә яшәүче гражданнар өчен һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законы, «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49,50,51 статьялары, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Торак урынының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясен куллану турында» 2025 елның 01 февралендәге 40 номерлы карары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен 2025 елда түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күләмен билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 571 842 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 1 143684 сум;

1.1.3. Өч кеше өчен - 1715 526 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2287 368 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 2 859 210 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 3 431 052 сум;

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 4 002 894 сум;

1.1.8. Сигез кешелек гаилә өчен - 4 574 736 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме исәпләү буенча 23471,30 сум тәшкил итә.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләре кабул ителгәнчегә кадәр, торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарны аз керемле дип тану өчен җаваплы вазыйфаи затларга (хезмәткәрләргә) гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның һәр әгъзасына туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм әлеге карар белән билгеләнгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен кулланырга.

3. «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында» Балтач районы башкарма комитетының 2024 елның 14 мартындагы 106 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2025 елның «27» 03
122 номерлы карарына
кушымта

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының 2025 елда чик күрсәткечләрен билгеләү МЕТОДИКАСЫ

1. Найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясен исәпләү күрсәткече (алга таба - исәпләү күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП x РС x РЦ, биредә

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешнең уртача шартларына туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе (Балтач районы башкарма комитетының 2025 елның 27 февралендәге 95 номерлы карары нигезендә 31769 сум тәшкил итә).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 31769 x18 = 571842 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 36 = 1 143 684 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 54 = 1 715 526 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 72 = 2 287 368 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 90 = 2 859 210 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 108 = 3 431 050 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 126 = 4 002 894 сум

з) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 31769 x 144 = 4 574 736 сум

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең иң чик күрсәткече:

$ПД = 0,7 \times СЖ \times ПС / (1 - (1 + ПС)^{-КП}) / (0,3 \times РС)$, биредә

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер ай эчендә процент ставкасы (унарлы вакланма)

(Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы 21.02.2025 елга 21 %, ягъни аена 21/100/12 = 0,0175 га).

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны)

(Россия Федерациясе Үзәк Банкы мәгълүматлары буенча, уртача үлчәнгән срок – 2025 елның 1 гыйнварена торыш - 303,6 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

**Гаиләнең бер әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган кеременең чик кыйммәтен исәпләү**

| НП - торак урынының нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы | ПД - Кеременң чик күрсәткече (сум) (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 31769 | 21/100/12= 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,3 | |
| 18 | 571842 | 1 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,3 | 23471,30 |
| 36 | 1143684 | 2 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,6 | 23471,30 |
| 54 | 1715526 | 3 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 0,9 | 23471,30 |
| 72 | 2287368 | 4 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1,2 | 23471,30 |
| 90 | 2859210 | 5 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1,5 | 23471,30 |
| 108 | 3431052 | 6 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 1,8 | 23471,30 |
| 126 | 4002894 | 7 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 2,1 | 23471,30 |
| 144 | 4574736 | 8 | 31769 | 0,0175 | 303,6 | 0,7 | 2,4 | 23471,30 |